ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КОЗЯКОВО-ЧЕЛНИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422668, с. Козяково-Челны,
ул. Иванова, дом 26

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАЗАКЛАР ЧАЛЛЫСЫ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422668, Казаклар Чаллысы авылы,
Иванов урамы, 26 нче йорт,

Тел.: (84361) 32310, e-mail: Kcn.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Казаклар Чаллысы авылы №69 26.11.2025 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2024 елның 24 нче сентябрындагы «белешмә (өземтә) биру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламментын раслау турында» гы 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 31.07.2025 ел, №304-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 28.02.2022 ел, №175 карарына таянып Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 11.02.2022 №28пи карары белән «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында», Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Казак Чаллысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казак Чаллысы авыл җирлеге Башкарма комитетының «белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 24.09.2024 ел, № 6 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 2.5 бүлегенең 2.5.1 пунктының 4 пунктчасында "мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртү кирәк" сүзләрен «мөрәҗәгать

итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен бирү һәм аларны эшкәртү кирәк»сүзләренә алмаштырырга;

- 1.2 2.5.1 бүлегенең 2 пунктына 4.1 пунктчасы өстәргә

- «4.1 Мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси белешмәләре федераль башкарма хакимият органнарының, бюджеттан тыш дәүләт фондлары органнарының, Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнарының, шулай ук җирле үзидарә органнарының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча вәкаләтләрен үтәү өчен бердәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә мондый белешмәләр күрсәтелмичә, мондый затның яисә аның законлы вәкиленең ризалыгын алу күрсәтелгән максатларда мондый затның шәхси мәгълүматларын эшкәртү таләп ителми.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегенең Казак Чаллысы авылы, Иванов ур., 26 йорт; Иванай авылы, Калинин ур., 18 йорт; Бердибәк авылы, Мәктәп ур., 5 йорт; Уреево-Чаллы авылы, Гаврилов ур., 24 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Казаклар Чаллысы авыл җирлеге Башлыгы Ф.Х.Хәсәншин